СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 261 от 24.10.2018

на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Шәһәр төзелеше өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 24 маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 15 маддәсенең 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94 номерлы карары белән расланган “Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә”гә яраклы рәвештә, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районның җирле әһәмияттәге сораулары булуын һәм авыл җирлекләре биләмәләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бәяләмәсе булуын исәпкә алып һәм уздырылган җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре йомгаклары буенча, Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Генераль планын расларга (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында” 2017 елның 12 апрелендәге 113 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ